**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 20 февраль № 104

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәт тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 19 июль, 512 нче карары белән расланган «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәт тормышка ашыру» дәүләт программасына үзгәрешләрләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәт тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 19 июль, 512 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 3 октябрь, 741 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәт тормышка ашыру» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре</td>
<td>Программаны финанслауның гомуми күләме Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән 28,689 млн.сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>(млн.сум)
<table>
<tr><th>Ел</th><th>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</th></tr>
<tr><td>2015</td><td>5,615</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>4,370</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>4,491</td></tr>
</table>
</td>
</tr>
</table>

| | |
|---|---|
| 2018 | 4,616 |
| 2019 | 4,737 |
| 2020 | 4,860 |
| Барлы-<br>гы | 28,689 |

Искәрмә: финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм, Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен тәгаенләнергә тиеш»;

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

2015 – 2020 елларда Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән Программаны финанслауның гомуми күләме 28,689 млн.сум тәшкил итә, шул исәптән:

(млн.сум)

| Ел | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы күләме |
|---|---|
| 2015 | 5,615 |
| 2016 | 4,370 |
| 2017 | 4,491 |
| 2018 | 4,616 |
| 2019 | 4,737 |
| 2020 | 4,860 |

Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм, Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен тәгаенләнергә тиеш.

Моннан тыш, программа чараларын тормышка ашыруга чараларны үтәүчеләрнең төп эшчәнлеген финанслауга бүлеп бирелә торган акчаны файдалану күздә тотыла.»;

Программага кушымтада:

түбәндәге эчтәлекле 2.2.1 пункт өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «2.2.1. норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча | ТР Юстиция министрлыгы, РФ Юстиция министрлыгының ТР буенча идарәсе (килешү буенча) | 2016 – 2020 еллар | Елына үткәрелгән чара | | | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | | 0,4 | 0,4 | 0,4 | 0,4 | 0,4»; |

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| экспертларның еллык республика конкурсын оештыру һәм уздыру | | | | | | | | | | | | | | | | |

«Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән программа буенча барлыгы» юлында «26,689» саннарына «28,689» саннарына алмаштырырга;

Файдаланылган кыскартулар исемлегенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«РФ Юстиция министрлыгының ТР буенча идарәсе – Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\104.docx